**СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423190, с. Новошешминск, ул. Советская, 80
тел.: (84348) 2-31-00, факс: (8-4348) 2-20-22

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ**

423190,Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80
тел.: (8-4348) 2-31-00, факс: (84348) 2-20-22

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

«16» 2026 ел июленнән № 11- 74

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 91, 92 и 93 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карарының әлеге проектын 1 нче кушымта нигезендә беренче укылышта кабул кабул итәргә һәм гавами тыңлауларга чыгарырга.

2. Расларга:

- 2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның фикер алышуда катнашу тәртибен;

- 3 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру һәм аның буенча фиекр алышуда гражданнарның катнашу тәртибен.

3. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү

датасын 2026 елның 29 июленә, урынын Совет ур., 80 й., Яңа Чишмә муниципаль районы, Яңа Чишмә муниципаль районы, Татарстан Республикасы адресы буенча урнашкан Яңа Чишмә муниципаль районы Советының актлар залын, вакытын - 17.00 сәг. дип билгеләргә.

4. Гавами тыңлаулар үткәрү комиссиясен түбәндәге составта төзергә:

1) Попкова Надежда Ивановна, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы урынбасары - комиссия рәисе;

2) Осипова Мария Сергеевна, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының оештыру бүлеге баш белгече - комиссия секретаре;

3) Лобачева Ирина Игоревна, коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе - комиссия әгъзасы;

4) Пузикова Анна Сергеевна, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының кадрлар секторы мөдире - комиссия әгъзасы;

5) Юдинцева Ольга Александровна, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы юристы, комиссия әгъзасы;

5. Гавами тыңлаулар үткәрү комиссиясенә гавами тыңлаулар үткәрүне, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының күрсәтелгән карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

6. Законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиягә гавами тыңлауларда яңгыраган һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советына карауга кертергә.

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: https//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https//novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

9. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль Башлыгы районы — Е.А. Тарнавский

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль
районы Советының
2026 елның 16 июленнән
11-74 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары проекты

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 91, 92 һәм 93 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 16 октябрендәге 2-9 номерлы; 2016 елның 11 февралендәге 9-32 номерлы; 2016 елның 28 сентябрендәге 18-82 номерлы; 2016 елның 14 декабрендәге 20-103 номерлы; 2017 елның 17 апрелендәге 25-132 номерлы; 2017 елның 17 августындагы 28-150 номерлы; 2017 елның 14 декабрендәге 31-180 номерлы; 2018 елның 25 маендагы 37-209 номерлы; 2018 елның 13 декабрендәге 43-252 номерлы; 2019 елның 5 июлендәге 50-299 номерлы; 2020 елның 4 июнендәге 61-378 номерлы; 2021 елның 2 июнендәге 10-70 номерлы; 2021 елның 9 декабрендәге 16-124 номерлы; 2022 елның 7 июлендәге 24-181 номерлы; 2023 елның 16 мартындагы 32-245 номерлы; 2024 елның 27 мартындагы 43-332 номерлы; 2024 елның 13 декабрендәге 50-387 номерлы; 2025 елның 5 июнендәге 57-434 номерлы; 2025 елның 29 декабрендәге 5-29 номерлы карарлары редакциясендә) (алга таба – Устав) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1. Уставның 4 статьясындагы 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирле үзидарә гражданнар тарафыннан турыдан-туры ихтыяр белдерү формалары аша, шулай ук җирле үзидарә органнары аша гамәлгә ашырыла.»;

2. Уставның 26 статьясындагы 6 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Район Советы эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары җирле бюджетта Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнары классификациясе нигезендә башка чыгымнардан аерым юл белән карала.»;

3. Уставның 53 статьясына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитет җитәкчесе якларның килешүе буенча яки түбәндәгеләрнең гаризалары нигезендә суд тәртибендә вазыйфасыннан азат ителергә мөмкин:

1) Район Советы яки Район Башлыгы - Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә кагылышлы бозулар, шулай ук Россия Федерациясенең коррупциягә каршы көрәш турында законнары белән урнаштырылган чикләүләр, тыюлар, бурычларны үтәмәүгә бәйле рәвештә;

2) Татарстан Республикасы Башлыгы (рәисе) - Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга кагылышлы өлешендә җибәрелгән хокук бозуларга бәйле рәвештә, шулай ук коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәүгә бәйле рәвештә;

3) Башкарма комитет җитәкчесе - җирле үзидарә органнары һәм (яки) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләү шартларын бозуга бәйле рәвештә.»;

- 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Башкарма комитет җитәкчесе вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган яки аңа карата суд карары буенча сак астына алу яки вазыйфасыннан вакытлыча читләштерү рәвешендә процессуаль мәҗбүр итү чаралары кулланылган очракта, аның вәкаләтләре җирле үзидарәнең вазыйфаи заты яисә әлеге Устав нигезендә билгеләнә торган вәкаләтле муниципаль хезмәткәр тарафыннан вакытлыча башкарыла.»

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль
районы Советының
2026 елның 16 июленнән
11-74 номерлы карарына
2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм аның турында фикер алышуларда катнашу тәртибе

1. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары проектына тәкъдимнәр түбәндәге үрнәктәге төзәтмәләр таблицасы рәвешендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советына кертелә:

| т/б | Пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмә тексты | Төзәтмәне исәпкә алып, карар проекты тексты | Төзәтмә авторы (ФИА, адресы,телефоны, эш (уку) урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

423190, Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Советская ур., 80 й., 314номерлы каб. адресы буенча;

423190, Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Советская ур., 80 й., 314номерлы каб. почта адресы буенча;

факс буенча: 884348-2-22-32.

Тәкъдимнәр «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru халыкка җиткерелгән көннән алып эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгать вакыт аралыгында 2026 елның 29 июленә кадәр кабул ителә.

Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирелә:

423190, Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Советская ур., 80 й., 314номерлы каб. адресы буенча;

423190, Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Советская ур., 80 й., 314номерлы каб. почта адресы буенча;

факс буенча: 884348-2-22-32.

Гаризалар эш көннәрендә 8.00 дән 16.00 гә кадәр гавами тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 2 эш көненнән дә соңга калмыйча кабул ителә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль
районы Советының
2026 елның 16 июленнән
11-74 номерлы карарына
3 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру һәм гражданнарның аның турында фикер алышуларда катнашу тәртибе

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 19 статьясы нигезендә үткәрелә.

2. Гавами тыңлауларда үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы белән катнашучылар булып Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советына гавами тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 2 эш көненнән дә соңга калмыйча язма гаризалар тапшырган район халкы тора.

3. Гавами тыңлауларнда чыгыш ясау хокукыннан башка районның барлык кызыксынган кешеләре катнаша ала.

4. Катнашучыларны теркәү гавами тыңлаулар башланырга 1 сәгать кала башлана.

5. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы урынбасары гавами тыңлауларда рәислек итә.

6. Гавами тыңлаулар рәислек итүченең кереш сүзе белән ачыла, ул утырышта катнашучыларга фикер алышына торган мәсьәләнең асылы, тыңлауларны үткәрү тәртибе турында хәбәр итә.

7. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу өчен рәислек итүче тәкъдиме буенча секретариатның җитәкчесе һәм бер әгъзасы составында ачык тыңлаулар секретариаты сайлана.

8. Төп доклад белән эшче төркем әгъзасы чыгыш ясый.

9. Чыгыш хокукы белән гавами тыңлауларда катнашучылар, гариза бирү вакытына карап, чират тәртибендә үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чакырыла.

10. Гавами тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 5 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел.

11. Гавами тыңлауларнда катнашучылар рәислек итүче рөхсәте белән чыгыш ясаганнан соң чыгыш ясаучыларга сораулар бирергә хокуклы.

12. Гавами тыңлауларда катнашучылар гавами тыңлаулар барышына тыкшынырга, аларны үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

13. Гавами тыңлаулар уздырганда тәртипне үтәү ачык тыңлауларда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

14. Гавами тыңлауларда катнашучылар тарафыннан уздыру тәртибе бозылган очракта, рәислек итүче аларны утырыш залыннан чыгаруны таләп итәргә хокуклы.

15. Чыгышлар тәмамланганнан соң, рәислек итүче гавами тыңлаулар секретариаты җитәкчесенә гавами тыңлаулар барышында әйтелгән тәкъдимнәрне, искәрмәләрне ачыклау өчен сүз бирә ала.

16. Гавами тыңлауларда катнашучыларның барлык кисәтүләре һәм тәкъдимнәре гавами тыңлаулар беркетмәсенә кертелә. Беркетмә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы материалларында билгеләнгән тәртиптә саклана.

17. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә эшче төркем тарафыннан әзерләнә.

18. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә халыкка җиткерелергә тиеш.

19. Гавами тыңлаулар үткәрүне оештыру һәм матди-техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы тарафыннан гамәлгә ашырыла.